РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕНЫРТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422063, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Б.Нырты, ул. М Джалиля, д.13
тел. (84362) 45-2-32

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ НЫРТЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422063, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Нырты авылы, М Җәлил урамы, 13 йорт
тел. (84362) 45-2-32

e-mail: Bnir.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ | КАРАР
16.12.2024 | №28

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Нырты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты турында 23.10.2024 елгы №23 карары проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен карап, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 нче елның 6 нчы октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советының 2021 елның 17 декабренда кабул ителгән 31 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында» карары белән расланган Олы Нырты авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны “Интернет”мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:
- ТР, Саба районы, Олы Нырты авылы, М.Җәлил урамы, 13а йорт;
- ТР, Саба районы, Завод-Нырты авылы, Заводская урамы, 17В йорт;
- ТР, Саба районы, Урта Нырты авылы, Х.Такташа урамы, 22Б йорт;
- РТ, Саба районы, Чәбия Чүрчи авылы, А.Каримуллин урамы, 27А йорт.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләрне дәүләт теркәве өчен әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе юстиция Министрлыгының идарәсенә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Башлыгы, Р.З.Сәфәргалиевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Олы Нырты
авыл җирлеге башлыгы Р.З.Сәфәргалиев

РАСЛАРГА
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Олы Нырты
авыл җирлеге Советының 2024
елның
16 декабрендә №28 карары белән

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы
Нырты авыл җирлеге Уставына кертелә торган
үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. 5 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 21 пунктча өстәргә) :
"21) «шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә граждannар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;
2. 19 статьяның 5 пунктының икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1 – 7 һәм 9.2 пунктларында»сүзләренә алмаштырырга.;
3. 34 статьяның 1 пунктындагы 26 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::
«26) матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) Челтәр басмасын булдыру;»;
4. 41 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12.1 пунктчасы өстәргә::
"12.1) аның чит ил агенты статусын алуы;".